# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Җир реформасы турында" Татарстан
Республикасы Законына үзгәрешләр
һәм өстәмәләр кертү хакында

"Җир реформасы турында" Татарстан Республикасы Законын Татарстан Республикасы Конституциясенә, "Татарстан Республикасында милек турында", "Җир өчен түләү турында" Татарстан Республикасы законнарына туры китерү һәм җир мөнәсәбәтләрен җайга салу өлкәсендә законнар чыгаруны камилләштерү максатында "Җир реформасы турында" Татарстан Республикасы Законына түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1. 2 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2 статья. Татарстан Республикасында җир - бөтенхалык милке һәм ул гражданнарның хосусый (шәхси, уртак - күмәк, өлешчә күмәк) милкендә, дәүләт милкендә, җирле милектә һәм җәмәгать берләшмәләре милкендә булырга мөмкин.

Җирне биләү, җирдән файдалану һәм җиргә хуҗа булу Татарстан Республикасының Җир кодексында һәм Татарстан Республикасының башка законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Җәмәгатьчелек мәнфәгатьләреннән чыгып, Татарстан Республикасында милеккә, биләүгә һәм файдалануга тапшырыла торган җир кишәрлекләренең чикләнгән күләмнәре һәм нормалары билгеләнә.

2. 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3 статья. Республика территориясендәреспубликаара һәм дәүләтара максатлар өчен җирләр тиешле шартнамәләрдә һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән шартларда һәм тәртиптә бирелергә мөмкин."

3.4 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4 статья. Крестьян /фермер/ хуҗалыгы, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен, бакчачылык, яшелчәчелек, терлекчелек, шәхси торак төзелеше, дача, гараж төзелеше, эшкуарлык эшчәнлеге алып бару өчен торакны хосусыйлаштырганда һәм закон белән тыелмаган башка максатларда җир кишәрлекләре гражданнар милкенә, гомерлек мирас итеп биләүгә яисә файдалануга Татарстан Республикасы законнары нигезендә бирелә.

Җирне элеккеге хосусый милекчеләргә һәм аларның варисларына кире кайтарып бирү рөхсәт ителми, җир кишәрлекләрен алар үз милекләренә гомуми нигезләрдә ала алалар."

4.5 статья төшереп калдырыла.

5.6 статьяны 5 статья дип санарга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5 статья. Колхозларга, башка кооператив авыл хуҗалыгы предприятиеләренә, акционер хуҗалык җәмгыятьләренә,ширкәтләренә һәм башка хуҗалык берләшмәләренә, шул исәптән дәүләт авыл хуҗалыгы предприятиеләре нигезендә оештырылганнарына җир кишәрлекләре күмәк /уртак яисә өлешле/ милеккә бирелергә мөмкин.

Коллективның һәр әгъзасы крестьян /фермер/ хуҗалыгы оештыру максатында аннан чыккан очракта җир кишәрлеге сыйфатында үз өлешен алырга хаклы. Бу кагыйдә, Татарстан Республикасы законнарында каралган очраклардан гайре, хуҗалык итүнең элеккеге рәвешләрен саклап калган авыл хуҗалыгы предприятиеләре хезмәткәрләренә дә кагыла.

6.6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"<u>6 статья</u>. Җир кишәрлекләре чит ил гражданнары һәм хокукый затлары, уртак предприятиеләр, халыкара берләшмәләр һәм оешмалар милкендә булырга мөмкин".

7.7 статьяны төшереп калдырырга.

8.8 статьяны 7 статья дип санарга һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"<u>7 статья.</u> Гражданнар милкенә җир халык депутатлары Советлары яки аларның вәкаләтле органнары тарафыннан түләүсез һәм түләүле тапшырыла.

Гражданнар милкенә түбәндәгеләр өчен җир түләүсез тапшырыла:

әлеге Законның 4 статьясында күрсәтелгән максатлар өчен, статьяның дүртенче өлешендә каралган очраклардан тыш, мәйданнары саклanып калган килеш, элек бирелгән җир кишәрлекләре;

крестьян /фермер/ хуҗалыгы алып бару өчен, җиргә күмәк /уртак, өлешле/ милек барлыкка килгән очракта, авыл хуҗалыгы җитештерүен бергәләп алып бару өчен, крестьян хуҗалыгының, хезмәт коллективының һәр әгъзасына исәпләгәндә җирне милеккә түләүсез тапшыруның район буенча билгеләнгән уртача нормасы чикләрендә;

Электән килгән крестьян хуҗалыкларында бу нормадан артып китә торган кишәрлекләр гомерлек мирас итеп биләүгә, даими файдалануга, аренда өчен крестьян /фермер/ хуҗалыгы башлыгына тапшырыла һәм алар, акча түләп, үз милекләренә алынырга мөмкин;

билгеләнгән норма чикләрендә, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык, терлекчелек өчен, авыл җирендә шәхси торак төзелеше өчен. Шул ук вакытта җирдән элек файдаланучыларга аларның җирен алудан килгән зыянны каплау законда билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Түләүле җир кишәрлекләре гражданнар милкенә түбәндәгеләр өчен тапшырыла:

крестьян /фермер/ хуҗалыгын алып бару, җиргә күмәк /уртак, өлешле/ милек барлыкка килгән очракта авыл хуҗалыгы җитештерүен уртак алып бару максатында крестьян хуҗалыгының, хезмәт коллективының һәр әгъзасына исәпләгәндә җирне милеккә түләүсез тапшыруның район буенча билгеләнгән уртача нормасыннан артып киткән мәйдан өчен;

дача һәм гараж төзелеше өчен;

авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү белән бәйле булмаган эшкуарлык эшчәнлеге өчен;

шәһәрләрдә һәм шәһәр тибындагы поселокларда шәхси торак төзелеше өчен;

закон белән тыелмаган башка максатлар өчен.

9.8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"8 статья. Җир кишәрлекләрен беренче мәртәбә сатып алу һәм хосусый милек итеп түләүсез тапшыру, гомерлек мирас итеп биләүгә яки милеккә тапшырылган җирнең варисы булу, җир кишәрлекләрен милек хуҗалары тарафыннан сату халык депутатларының җирле Советлары яки аларның әлеге территориядәге вәкаләтле органнары тарафыннан Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла".

10. 10 статьяны 9 статья дип санарга һәм "җир биләүчеләр" сүзе алдыннан "җир милекчеләре" сүзләрен өстәргә.

11. 11 статьяны 10 статья дип санарга һәм аңа түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

"... түләүле" сүзеннән соң беренче өлешкә "җир милекчеләре" дигән сүзләр өстәргә;

икенче өлештә "республика закон актлары нигезендә акчаларның бер өлеше республика бюджетында үзәкләштерелергә мөмкин" сүзләрен "Республика программалары чикләрендә күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен бу акчаларның бер өлеше Татарстан Республикасы законнары нигезендә үзәкләштерелергә мөмкин" сүзләренә алмаштырырга;

өченче өлештәге "җир салымыннан югарырак булмаган чикләрдә" сүзләрен төшереп калдырырга.

I2. I2 статьяны 11 статья дип санарга һәм"җир биләүчеләр" сүзе алдыннан "җир милекчеләре" сүзләрен өстәргә.

I3. I3 статьяны I2 статья дип санарга һәм беренче өлештәге "тартып алынырга мөмкин" сүзләреннән соң "законда билгеләнгән тәртиптә" сүзләрен өстәргә; "өлеш" сүзе алдыннан "биләвендә һәм файдалануында булган"сүзләрен өстәргә;

өченче өлешне дүртенче өлеш дип санарга;

түбәндәге редакциядә өченче өлеш кертергә:

"Гражданнар милкенә тапшырылган җир закон билгеләгән тәртиптә тартып алынырга мөмкин".

I4. I4 статьяны I3 статья дип санарга.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1993 елның 21 мае
№ I86I-XII